# ГӨЛЛӘРЕМ

Алсу таңлы, хуш чәчкәле,
Тәрәзәмдә гөлләрем.
Гөлләремә иркәләнеп,
Үтә минем көннәрем ....

*Кушымта:*
Мин елмайсам елмайлар,
Сөенсәм сөенеләр.
Кояшның якты нурына,
Гөлләрем үреләләр ...

Сездә бармы хуш чәчәкле,
Иркәләргә гөлегез ?
Гөлләремә рәхим итеп,
Өйгә безнең килегез ...

Сары таҗлы, биш чәчәкле,
Тәрәзәмдә бер гөлем .
Гөлләремә генә карап,
Үсә минем күңелем ...